**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.09.2016 № 925-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының 2012 елның 20 апрелендәге № 143-п боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының Стационар чыганаклардан атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгармаларына рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының норматив хокукый актларын законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының 2012 елның 20 апрелендәге № 143-п боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының Стационар чыганаклардан атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгармаларына рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына (Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының 2012 елның 23 октябрендәге№ 420-п, 2013 елның 7 маендагы № 266-п, 2013 елның 24 сентябрендәге № 539-п боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлектә:

1.1 пунктта “контрольгә” сүзен “күзәтчелеккә” сүзе белән алыштырырга;

1.3 пунктта:

1.3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.3.1. Министрлыкның урнашкан урыны: Казан ш., Павлюхин ур., й.75.

Министрлыкка документлар һәм дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча мөрәҗәгать итү өчен почта адресы: 420049, Татарстан Республикасы, Казан ш., Павлюхин ур., й.75.

Министрлыкның эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән тыш көн саен, дүшәмбе-пәнҗешәмбе 9.00 сәгатьтән 18.00 кадәр, җомга 9.00 сәгатьтән 16.45 кадәр, төшке аш 12.00 - 12.45.

Җәмәгать транспортында бару:
"Павлюхин" тукталышына кадәр:
автобуслар №№ 2, 4, 5, 25, 31, 37, 43, 47, 69, 69а, 74, 74а, 77;
троллейбуслар №№ 6, 8, 12;
метро «Сукно Бистәсе» станциясенә кадәр.
Керү шәхесне таныклый торган документ буенча.";
1.3.3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1.3.3. Министрлыкның "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә "Татарстан Республикасының рәсми порталы" Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына керә торган рәсми сайты адресы (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты һәм "Интернет" челтәре, туры китереп): http://eco.tatarstan.ru, электрон почта адресы: eco@tatar.ru.";

1.3.5 пунктчаны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

"Мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат үз эченә дәүләт хезмәте күрсәтү турында әлеге Регламентның 1.1, 1.3.1, 1.3.2, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган мәгълүматларны ала.";

1.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясенең Салым кодексы (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 1998, № 31, ст. 3824, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

1999 елның 4 маендагы № 96-ФЗ "Атмосфера һавасын саклау турында" Федераль закон (алга таба - Федераль закон № 96-ФЗ) (Россия Федерациясе законнары җыеелмасы, 1999, № 18, ст. 2222, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2002 елның 10 январендагы № 7-ФЗ "Әйләнә-тирә мохитне саклау турында" Федераль закон (алга таба - Федераль закон № 7-ФЗ) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2002, № 2, ст. 133, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2010 елның 27 июлендәге № 210-ФЗ "Дәүләт хезмәте һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында" Федераль закон (алга таба - Федераль закон № 210-ФЗ), (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2010, № 31, ст. 4179, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 елның 2 мартындагы №183 "Атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгармаларының һәм аңа зарарлы физик йогынтыларның нормативы турында" карары (алга таба - РФ Хөкүмәтенең № 183 карары), (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2000, №11, ст. 1180, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 елның 21 апрелендәге №373 "Атмосфера һавасына зарарлы йогынтыларны һәм аларның чыганакларын дәүләт исәбенә алу турында нигезләмәне раслау турында" карары (алга таба - РФ Хөкүмәтенең №373 карары), (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2000, №18, ст. 1987);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 6 маендагы № 352 "Федераль башкарма хакимият органнары тарафыннан, Атом энергиясе буенча Дәүләт корпорациясе "Росатом" тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнаша торган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең исемлеген раслау һәм аларны күрсәткән

өчен түләү күләмен билгеләү турында” карары (алга таба - РФ Хөкүмәтенең № 352 карары), (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2011, № 20, ст. 2829);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 16 маендагы № 373 “Дәүләт функцияләрен башкаруның административ регламентларын һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау турында” карары (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2011, №22, ст.3169, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Табигый ресурслар һәм экология министрлыгының 2011 елның 25 июлендәге № 650 “Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) чыгармаларга (радиоактив матдәләрдән тыш) рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламентын раслау турында” боерыгы (алга таба – РФ Табигать министрлыгы боерыгы №650), (Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, 2012, №14, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Табигый ресурслар һәм экология министрлыгының 2011 елның 8 сентябрендәге № 727 “Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалык эшчәнлеген һәм бүтән төр эшчәнлекне гамәлгә ашырганда әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган һәм федераль дәүләт экологик күзәтчелегенә карый торган объектлар исемлеген раслау турында” боерыгы (алга таба – РФ Табигать министрлыгы боерыгы № 727), (Ресурслар белән дәүләт идарәсе, 2013,  махсус чыгарылыш, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Табигый ресурслар һәм экология министрлыгының 2015 елның 29 сентябрендәге № 414 “Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең рөхсәт чигендәге чыгармаларны һәм вакытлыча килешенгән чыгармаларны билгеләү буенча Административ регламентын раслау турында” боерыгы (алга таба – РФ Табигать министрлыгы боерыгы № 414) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (WWW.PRAVO.GOV.RU), 2015, 29 декабрь);

Татарстан Республикасы Экология кодексы (Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы, 2009, № 1, ст. 5, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 06 июлендәге № 325 “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы мәсьәләләре” карары белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы турында нигезләмә  (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмерләре һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы” журналы, 2005, № 28, ст.0654, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 02 ноябрендәге № 880 “Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе, (алга таба – Тәртип)  (“Татарстан

Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмерләре һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы" журналы», 2010, № 46, ст. 2144, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

1.5 пунктта:

5нче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"**рөхсәт чигендәге чыгарма** – атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдә чыгармасы нормативы, ул химик матдәнең яисә химик матдәләр катнашмасының, микроорганизмнарның, бүтән төр матдәләрнең стационар чыганактан һәм (яки) стационар чыганаклар җыелмасыннан атмосфера һавасына чыгару өчен рөхсәт ителә торган күләме яки массасы буларак, радиоактив матдәләрнең активлыгы күрсәткече буларак билгеләнә һәм аны үтәгәндә, атмосфера һавасын саклау өлкәсендә таләпләрне үтәү тәэмин ителә;";

түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

**техник хата –** дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсе) кертелгән мәгълүматларның мәгълүматлар керткәндә нигезләнелгән документтагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (ялгыш язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата);

**дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны** – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү һәм бирү, консультацияләр бирү тәрәзәсе (алга таба – КФҮ ерактагы эш урыны).

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә гариза бирүченең № 210-ФЗ Федераль законың 2 маддәсе 1 пункты белән каралган дәүләте хезмәтен күрсәтү турында запросы аңлана. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гаризаның тәкъдим ителгән формасы әлеге Регламентка №2 кушымтада бирелде.";

2 бүлектә:

2 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты";

"Стандарт таләбе атамасы" графасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы";

"Стандарт таләбе эчтәлеге" графасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Стандартка таләпләр эчтәлеге";

2.1 пунктта "Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт" графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"№ 96-ФЗ Федераль законның 14 ст.; № 7-ФЗ Федераль законның 6, 22, 23 ст.; РФ Хөкүмәтенең №183 карары белән расланган Нигезләмәнең 9 п.; РФ Хөкүмәтенең № 373 карары; РФ Табигать министрлыгының № 727 боерыгы; Нигезләмәнең 3.3 пунктының 3.3.7 пунктчасы"

2.2 пунктта "Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт" графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"№ 96-ФЗ Федераль законның 14 ст.; Нигезләмәнең 3.3 пунктының 3.3.7 пунктчасы";

2.4 пунктта:

“Стандарт таләбе атамасы” графасын “, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы, туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары тарафыннан каралган очракта” сүзләре белән тулыландырырга;

“Стандарт таләбе эчтәлеге” графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Рөхсәт бирү гариза кергән вакыттан соң 22 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Рөхсәтне кабат рәсмиләштерү гариза кергән вакыттан соң 10 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Рөхсәт дубликатын бирү гариза кергән вакыттан соң 10 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү срогын туктатып тору каралмаган”;

2.5 пунктта:

“Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты таләбе атамасы” графасын “,гариза бирүче тарафыннан аларны алу чаралары, шул исәптән электрон формада, аларны күрсәтү тәртибе” сүзләре белән тулыландырырга;

“Стандартка таләпләр эчтәлеге” графасын түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

“Дәүләт хезмәте алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә ала ала. Бланкның электрон формасы Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырылган.

Гариза һәм кушымта итеп бирелә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырыла (җибәрелә) ала:

шәхсән (гариза бирүче исеменнән ышаныч кәгазе нигезендә эш йөртүче зат тарафыннан);

почта аша заказлы хат белән, аны тапшыру турында белдереп.

гариза бирүче тарафыннан гариза һәм документлар шулай ук көчәйтелгән махсус электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә гомуми мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәре һәм “Бердәм дәүләт хезмәте һәм муниципаль хезмәт порталы” аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.”;

“Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгеләүче норматив акт” графасы эчтәлеген төшереп калдырырга;

2.6 пунктта:

“Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы” графасын “, шулай ук гариза бирүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны күрсәтү тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма” сүзләре белән тулыландырырга;

“Стандарт таләпләре эчтәлеге” графасының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Хуҗалык һәм бүтән төр эшчәнлек объектларында урнашкан, федераль дәүләт экологик күзәтчелегенә карамый торган стационар чыганаклардан атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләрнең рөхсәт чигендәге

чыгармаларын билгеләү турында Татарстан Республикасы буенча Ростабигать күзәтчелеге идарәсе боерыгы (Татарстан Республикасы буенча Ростабигать күзәтчелеге идарәсендә).”;

“Стандартка таләпләр эчтәлеге” графасын түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

“Гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән.

Гариза бирүчедән югарыда саналган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән төр оешмалар карамагында булган документларны таләп итү тыела”;

“Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт” графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“№ 210-ФЗ Федераль законның 7 ст. 1 өлеше 2п.”;

2.8 пунктта “Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт” графасы эчтәлеген төшереп калдырырга;

2.9 пунктта :

“Стандартка таләпләр эчтәлеге” графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Дәүләт хезмәтен туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

1. Рөхсәт бирүдән баш тарту өчен нигезләр булып тора:

- билгеләнгән тәртиптә расланган РЧЧ нормативлары һәм чыгармаларга лимитларның гамәлдә булу срогы бетү;

- РЧЧ нормативларына этаплап ирешүнең Министрлык тарафыннанан расланган сроклары булмау;

- атмосферага чыгармалар составында гариза бирүче тапшырган, билгеләнгән тәртиптә расланган РЧЧ нормативларында һәм/яки чыгармаларга лимитларда күрсәтелмәгән пычраткыч матдәләр ачыклану;

- атмосфера һавасын саклауга производство контроле булмау;

- билгеләнгән РЧЧ нормативларын һәм/яки чыгармаларга лимитларны арттыруны ачыклау, үлчәнешләр төгәлсезлеген исәпкә алып;

- гариза бирүченең атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгармаларын этаплап киметүнең чыгармаларына лимит билгеләнә торган һәр матдә буенча РЧЧ нормативларына этаплап ирешүне тәэмин итә торган планнарын, РЧЧ нормативларына этаплап ирешүнең Министрлык тарафыннан расланган срокларын үтәмәве, яисә гамәлгә ашырылган мероприятиеләрнең планлаштырылган нәтиҗәлелегенә ирешмәве;

- гариза бирүче тарафыннан тапшырыла торган документларда нинди дә булса мәгълүматлар булмау яки дөрес булмаган мәгълүматлар булу;

- тапшырылган документларның табигать саклау законнарына туры килмәве.

2. Рөхсәтне кабат рәсмиләштерүдән баш тарту өчен, гариза бирүче тарафыннан тапшырыла торган документларда нинди дә булса мәгълүматлар булмау яки дөрес булмаган мәгълүматлар булу нигез булып тора.

3. Рөхсәтнең гамәлдә булуын яңартудан баш тарту өчен, гариза бирүче тарафыннан тапшырыла торган документларда нинди дә булса мәгълүматлар булмау яки дөрес булмаган мәгълүматлар булу нигез булып тора”;

“Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт” графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“№ 96-ФЗ Федераль законның 14 ст.; РФ Табигать министрлыгының № 650 боерыгы белән расланган Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) чыгармаларга (радиоактив матдәләрдән тыш) рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Административ регламенты; РФ Табигать министрлыгының №414 боерыгы белән расланган Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең рөхсәт чигендәге чыгармаларны һәм вакытлыча килешенгән чыгармаларны билгеләү буенча Административ регламенты”;

2.10 пунктта “Стандартка таләпләр эчтәлеге” графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Рөхсәт биргән өчен 3500 күләмендә дәүләт пошлинасы алына.

Дәүләт пошлинасын күчерү өчен реквизитлар:

Р/счет 40101810800000010001

Банк получателя Отделение НБ Республика Татарстан

БИК банка 049205001

Получатель: УФК по РТ (Минэкологии РТ)

ИНН получателя 1659036508

КПП получателя 165901001

Бюджет классификациясе коды:

701 1 08 07262 01 1000 110

Рөхсәт биргән өчен дәүләт пошлинасы түләгәндә, түләү поручениесендә “Түләү билгеләнеше”ендә күрсәтергә: Атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) чыгармаларга рөхсәт бирү өчен дәүләт пошлинасы”;

2.13 пунктта:

“Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы” графасын “, шул исәпән электрон формада” сүзләре белән тулыландырырга;

“Стандартка таләпләр эчтәлеге” графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Гариза кергән көнне”;

2.14 пунктта:

“Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы” графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрнең көтү һәм кабул ителү урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турында законнары нигезендә инвалидларга әлеге объектларга үтү мөмкинлеген тәэмин итүгә таләпләр, мондый хезмәт күрсәтүләр тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыруга һәм рәсмиләштерелүенә таләпләр”;

“Стандартка таләпләр эчтәлеге” графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Дәүләт хезмәте күрсәтү һаваны кондицияләү системасы, янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазланган биналарда һәм урыннарда гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү урынына инвалидларның каршылыксыз үтү

мөмкинлеге (биналарга уңайлы керү-чыгу һәм алар эчендә күчеп йөрү) тәэмин ителә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарга урнаштырыла, шул исәптән инвалидларның чикле мөмкинлекләрен исәпкә алып.”;

2.15 пунктта:

“Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы” графасын “,шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешләре саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтен дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәктә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникатив технологияләр кулланып” сүзләре белән тулыландырырга;

“Стандартка таләпләр эчтәлеге” графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Дәүләт хезмәтенең һәркем ала алырлык булуы күрсәткечләре булып тора:

кабул итү бара торган биналарның җәмәгать транспортына үтү мөмкинлеге булган зонада урнашуы;

кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булу;

дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат стендларында, “Интернет” челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, Министрлыкның рәсми сайтында тулы мәгълүмат булу;

гаризаны электрон төрдә бирү мөмкинлеге;

гариза бирүче гариза һәм документларны Татарстан Республикасы дәүләт хезмәте һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшырган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен электрон төрдә Татарстан Республикасы дәүләт хезмәте һәм муниципаль хезмәтләр порталында шәхси кабинет аша алу мөмкинлеге (гариза һәм документларны электрон документлар формасында Татарстан Республикасы дәүләт хезмәте һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшыру мөмкинлеген тормышка ашырганнан соң);

хезмәт күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтеп йөрерлек булуы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты күрсәткечләре булып тора:

документларны кабул итү һәм карау срокларын саклау;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу срогын саклау;

дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан әлеге Регламентны бозу турында прецедентлар (дәлилләнгән шикаятьләр) булу (прецедентлар, шикаятьләр саны Министрлыкның һәм Министрлык территориаль идарәләренең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затларының гомуми санына бәйләнештә);

гариза бирүченең белгечләр белән үзара бәйләнешләре саны:

гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен турыдан-туры алганда – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпләмичә);

гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – юк (консультацияләрне исәпләмичә);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны Татарстан Республикасы дәүләт хезмәте һәм муниципаль хезмәтләр порталында шәхси кабинет аша җибәргәндә:

1. әгәр гариза һәм документларның күчермәләре, Федераль закон № 63-ФЗ һәм Федераль закон № 210-ФЗ таләпләренә туры китереп электрон имза белән имзаланган (расланган) электрон документлар формасында җибәрелсә – турыдан-туры үзара бәйләнеш таләп ителми;

2. әгәр гариза һәм документларның күчермәләре Федераль закон № 63-ФЗ һәм Федераль закон № 210-ФЗ таләпләренә туры китереп, электрон имза белән имзаланмаган (расланмаган) электрон документлар формасында җибәрелсә – бердән артык түгел.

Гариза бирүче белән бер үзара бәйләнешнең дәвамлылыгы – 15 минуттан артык түгел.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан http://www. eco.tatarstan.ru сайтында, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында алынырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп, күпфункцияле үзәк аша, КФҮ ерактагы эш урыннары аша башкарылмый";

"Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт" графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Тәртипнең 2.4 пунктының "п" пунктчасы";

2.16 пунктта "Стандартка таләпләр эчтәлеге" графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны һәм сканерланган документларны электрон рәвештә Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрү мөмкинлеге бар, аннан соң документларның оригиналларын рөхсәт алганда күрсәтеп";

3 бүлектә:

бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3. **Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары, аларны башкару тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында башкару үзенчәлекләре";**

3.1 пунктта:

3.1.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3.1.1. Стационар чыганаклардан атмосфера һавсына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгармаларына рөхсәт бирү буенча административ процедура үз эченә түбәндәге процедураларны ала:

гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;

гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

ведомствоара запросларны формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү;

гариза бирүченең тапшырылган документлары комплектлылыгын тикшерү, гариза бирүченең материалларын карау, рөхсәтне (рөхсәт бирүдән баш тартуны) әзерләү һәм раслау,

гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;

техник хатаны төзәтү.”;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү һәм гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә.

Гариза бирүче, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультация алу өчен, Министрлыкның әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны нормалаштыру бүлегенә (алга таба – Бүлек) шәхсән, почта буенча, телефон буенча, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, Бердәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (фунцияләр) порталы аша һәм (яки) электрон почта ярдәмендә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече, гариза бирүченең мөрәҗәгать итү ысулына бәйле рәвештә, шәхсән, телефон, электрон почта буенча һәм (яки) хат белән, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән гаризаның формасы һәм эчтәлеге буенча, һәм гариза бирүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән аны рәсмиләштерү өлешендә.

Бу пункт белән билгеләнә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гаризаның формасы буенча һәм дәүләт хезмәте күрсәтүне алу өчен башка сораулар буенча консультация, шулай ук күрсәтелгән ярдәм.”;

3.3 пунктта:

3.3.1 пунктчаның беренче абзацында “эш башкару бүлеге” сүзләрен “документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге” сүзләре белән алыштырырга;

3.3.1 пунктчаның өченче абзацын төшереп калдырырга;

3.3.2 пунктчаның беренче абзацында “эш башкару бүлеге” сүзләрен “документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге” сүзләре белән алыштырырга;

3.4 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасы буенча Ростабигать күзәтчелеге Идарәсенең федераль дәүләт экологик күзәтчелегенә карамаган, хуҗалык эшчәнлеген һәм бүтән төр эшчәнлекне гамәлгә ашыра торган объектларда урнашкан стационар чыганаклардан атмосфера һавасына рөхсәт чигендәге зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгармаларын билгеләү турында боерыгын Татарстан Республикасы буенча Ростабигать күзәтчелеге Идарәсенә тапшыру турында;”;

Түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

“Соратылган документлар (мәгълүматлар) мәгълүматларны бирүче тарафыннан, җибәрелгән запрослар нигезендә, законнар белән билгеләнгән срокларда тапшырыла.”;

3.5.пунктта:

3.5.4 пунктчада:

беренче абзацта “эш башкару бүлеге” сүзләрен “документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге” сүзләре белән алыштырырга;

икенче абзацта “өч көн” сүзләрен “өч эш көне” сүзләре белән алыштырырга;

өченче абзацта “эш башкару бүлеге” сүзләрен “документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге” сүзләре белән алыштырырга;

3.5.5 пунктчада:

беренче абзацта “эш башкару бүлеге” сүзләрен “документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге” сүзләре белән алыштырырга;

дүртенче абзацта “бер көн” сүзләрен “бер эш көне” сүзләре белән алыштырырга;

3.5.6 пунктчаның җиденче абзацында “15 көн” сүзләрен “15 эш көне” сүзләре белән алыштырырга;

3.5.8 пунктчаның икенче абзацында “бер көн” сүзләрен “бер эш көне” сүзләре белән алыштырырга;

3.5.9 пунктчаның икенче абзацында “бер көн” сүзләрен “бер эш көне” сүзләре белән алыштырырга;

3.5.10 пунктчада:

алтынчы абзацта “эш башкару бүлеге” сүзләрен “документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге” сүзләре белән алыштырырга;

җиденче абзацта “бер көн” сүзләрен “бер эш көне” сүзләре белән алыштырырга;

сигезенче абзацта “эш башкару бүлеге” сүзләрен “документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге” сүзләре белән алыштырырга;

3.6 пунктта:

3.6.2 пунктчада:

беренче абзацта “эш башкару бүлеге” сүзләрен “документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге” сүзләре белән алыштырырга;

икенче абзацта “бер көн” сүзләрен “бер эш көне” сүзләре белән алыштырырга;

3.7 пунктта:

3.7.4 пунктчаның сигезенче абзацында “дүрт көн” сүзләрен “дүрт эш көне” сүзләре белән алыштырырга;

3.7.6 пунктчаның икенче абзацында “бер көн” сүзләрен “бер эш көне” сүзләре белән алыштырырга;

3.7.7 пунктчаның икенче абзацында “бер көн” сүзләрен “бер эш көне” сүзләре белән алыштырырга;

3.7.8 пунктчаның алтынчы абзацында “бер көн” сүзләрен “бер эш көне” сүзләре белән алыштырырга;

3.8 пунктта:

3.8.2 пунктчаның икенче абзацында “эш башкару бүлеге” сүзләрен “документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге” сүзләре белән алыштырырга;

3.8.3 пунктчаның җиденче абзацында “дүрт көн” сүзләрен “дүрт эш көне” сүзләре белән алыштырырга;

3.8.4 пунктчаның икенче абзацында “бер көн” сүзләрен “бер эш көне” сүзләре белән алыштырырга;

3.8.5 пунктчаның икенче абзацында“бер көн” сүзләрен “бер эш көне” сүзләре белән алыштырырга;

3.8.6 пунктчада:

беренче абзацта “эш башкару бүлеге” сүзләрен “документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге” сүзләре белән алыштырырга;

икенче абзацта “бер көн” сүзләрен “бер эш көне” сүзләре белән алыштырырга;

өченче абзацта “эш башкару булеге” сүзләрен “документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге” сүзләре белән алыштырырга;

3.8.7 пунктчада:

беренче абзацта “эш башкару бүлеге” сүзләрен “документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге” сүзләре белән алыштырырга;

дүртенче абзацта “бер көн” сүзләрен “бер эш көне” сүзләре белән алыштырырга;

3.8.8 пунктчаның икенче абзацында “бер көн” сүзләрен “бер эш көне” сүзләре белән алыштырырга;

түбәндәге эчтәлектәге 3.9 пункты белән тулыландырырга:

“3.9. Дәүләт хезмәте күрсәтү күпфункцияле үзәк, КФҮнең ерактагы эш урыннары аша гамәлгә ашырылмый.”;

түбәндәге эчтәлектәге 3.10 пункты белән тулыландырырга:

“3.10. Техник хаталарны (ялгыш язу, басма хата, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.

3.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хата (ялгыш язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата) табылган очракта, гариза бирүче Бүлеккә тапшыра:

техник хатаны (ялгыш язу, басма хата, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза (кушымта 10);

гариза бирүчегә Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хата (ялгыш язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата) булган документ;

техник хата (ялгыш язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата) барлыгын исбатлый торган, юридик көчкә ия булган документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән мәгълүматларда техник хатаны (ялгыш язу, басма хата, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза гариза бирүче (вәкаләтле вәкиле) тарафыннан шәхсән, яисә почта аша (шул исәптән, электрон почтаны файдаланып), яисә Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшырыла.

3.10.2. Документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге белгече техник хатаны (ялгыш язу, басма хата, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гаризаны кушымтада бирелгән документлары белән кабул итә һәм бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасы аша электрон формада терки.

Бу пунктча белән билгеләнә торган процедура гариза кергән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, карауга җибәрелгән гариза.

3.10.3. Бүлек белгече документларны карый һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтүләр кертү максатында, төзәтелгән документны гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкиленә) шәхсән кул куйдырып тапшыра, гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкиленнән) техник хата (ялгыш язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата) булган документның оригиналын алып кала, яки Министрлыкка техник хата (ялгыш язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата) булган документның оригиналын тапшырганда, документны алу мөмкинлеге турында гариза бирүчегә почта аша (электрон почта ярдәмендә) хат җибәрә.

Бу пунктча белән билгеләнә торган процедура техник хата (ялгыш язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата) табылганнан соң яки теләсә кайсы кызыксынулы заттан җибәрелгән хата (ялгыш язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата) турында гариза алганнан соң, өч көн дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.”;

5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. **Гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтә торган Министрлыкның, шулай ук аның дәүләт хезмәте күрсәтә торган вазыйфаи затының, яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларнына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү.**

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының, яисә Министрлыкның дәүләт хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр тәртиптә – Министрлыкка шикаять бирү хокукына ия. Дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле рәвештә министр кабул иткән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауларга) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән, түбәндәге очракларда:

1) гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризасын теркәү срогын бозу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогын бозу;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән каралмаган документлар таләп итү;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен аларны тапшыру Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән каралган документларны гариза бирүчедән кабул итүдән баш тарту;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән федераль законнар һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән каралмаган нигезләрдә баш тарту;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә, гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән каралмаган түләү таләп итү;

7) Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу.

5.2. Шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, Министрлыкның рәсми сайтын, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталын, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталын файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итү вакытында алынырга мөмкин.

5.3. Дәүләт хезмәт күрсәтүе алучыларның шикаяте үз эченә түбәндәге мәгълүматларны алырга тиеш:

карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) шикаятьләнә торган Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең атамасы;

гариза бирүче физик затның фамилиясе, исеме, отчествосы (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүматлар яисә гариза бирүче юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында мәгълүматлар, шулай ук контакт телефоны номеры (номерлары), гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле электрон почта (булган очракта) адресы (адреслары) һәм почта адресы;

Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яисә дәүләт гражданлык хезмәткәренең шикаятьләнә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүматлар;

гариза бирүченең Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәвенә нигез булган дәлилләр.

5.4. Министрлыкка кергән шикаять аны теркәгән көннән соң 15 эш көне эчендә шикаятьләрне карау вәкаләтләренә ия булган вазыйфаи зат тарафыннан каралырга тиеш, ә Министрлыкның, аның вазыйфаи затының гариза бирүчедән документларны алудан баш тартуы яисә җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелү очрагында яки андый хаталарны төзәтү срогын бозуга шикаять белдерелү очрагында - аны теркәгән көннән соң 5 эш көне эчендә.

Гариза бирүче тарафыннан гариза бирүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яисә аларның күчермәләре тапшырыларга мөмкин.

5.5. Шикаять гариза бирүче тарафыннан шәхсән яисә аның вәкаләтле заты тарафыннан имзалана.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча Министрлык түбәндәге карарлырның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны кире кагу, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда Министрлык тарафыннан җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтү, аларны түләтү Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару формасында, шулай ук бүтән формаларда;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Гариза бирүчегә, бу пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң икенче көннән соңга калмыйча, шикаятьне карау нәтиҗәләре турында язмача формада һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон формада дәлилле җавап җибәрелә.

5.7. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре расланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләтләренә ия булган вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.”;

№№ 2 -5 Кушымталарда “М.У.” сүзләрен “М.У. (булган очракта)” сүзләре белән алыштырырга;

№9 Кушымтада:

“эш башкару бүлегенең” сүзләрен “документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлегенең” сүзләре белән алыштырырга;

“бер көн” сүзләрен “бер эш көне” сүзләре белән алыштырырга;

“15 көн” сүзләрен “15 эш көне” сүзләре белән алыштырырга;

“Атмосфера һавасына ЗМ РЧЧ нормативларын билгеләү буенча материалларны карау нәтиҗәләре буенча белешмә бирү турында запрос” сүзләрен “Атмосфера һавасына ЗМ РЧЧ нормативларын билгеләү турында боерыкны бирү турында запрос” сүзләре белән алыштырырга”;

түбәндәге эчтәлектәге кушымта белән тулыландырырга:

**«Татарстан Республикасы**
**Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының**
**Стационар чыганаклардан атмосфера һавасына**
**зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгармаларына**
**рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең**
**административ регламентына**
**Кушымта №10**

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрына

________________________________________

_____________________________________

(шәхси эшмәкәрләр өчен: Ф.И.О.,адрес (почта һәм (яки) электрон)

________________________________________________ юридик затлар өчен: оешма атамасы,

адрес (почта һәм (яки) электрон)

**Техник хатаны (ялгыш язу, басма хата, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза**

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышында җибәрелгән хата (ялгыш язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата) турында хәбәр итәм

_______________________________________________________________

(хезмәт күрсәтү атамасы)

Язылган: _____________________________________________________

_______________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар: ___________________________________________

_______________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны (ялгыш язу, басма хата, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтүне һәм Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документка тиешле үзгәрешләрне кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны кушымта итеп бирәм:

1.

2.

3.

Җибәрелгән техник хатаны (ялгыш язу, басма хата, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул иткән очракта, андый карарны җибәрүне сорыйм:

электрон документ җибәрү юлы белән, E-mail адресына:______________________;

расланган кәгазь күчермә рәвешендә почта аша түбәндәге адреска җибәреп: _____________________________________________________________.

Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), файдалану, тарату (шул исәптән бирү), исемсезләү, тыю, персональ мәгълүматларны юк итү, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларыда персональ мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле бүтән төр гамәлләр), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның алар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында карарлар кабул итүен дә кертеп, үз ризалыгымны, шулай ук мин вәкиле булып торган затның ризалыгын раслыйм.

Моның белән раслыйм: гаризага кертелгән, минем шәхескә һәм мин вәкиле булып торган зат шәхесенә кагылышлы мәгълүматлар, шулай ук минем тарафтан түбәндәрәк кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага кушымтада бирелгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны тапшыру моментына бу документлар гамәлдә һәм алардагы мәгълүматлар дөрес.

Миңа күрсәтелгән дәүләт хезмәте сыйфатын бәяләү буенча сораштыруда _______________телефоны буенча катнашырга ризалыгымны бирәм.

| | | |
|---|---|---|
| __________________ | _____________ | (_____________________) |
| (дата) | (имза) | (Ф.И.О.).”. |

2. Хокукый тәэмин итү бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары Р.И.Камаловка йөкләргә.

Министр Ф.С. Габделганиев